РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 ноябрь, 2024 ел №34

«Җир салымы турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 24 номерлы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Кукмара шәһәре Советының «Җир салымы турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 24 номерлы карарына (Кукмара шәһәре Советының 2023 елның 25 декабрендәге 30 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1.2 пунктчасында «(индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш, һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1.3 пунктчасында «һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләрен өстәргә»;

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә 1 ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев